| | | |
|---|---|---|
| Республика Татарстан<br><br>Совет Менделеевского муниципального района | | Татарстан Республикасы<br><br>Менделеевск муниципаль районы Советы |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 3 ноябреннән Менделеевск ш. №15

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
«Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Уставының 8 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советының 2018 елның 31 августыннан 22 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, 2013 елның 27 маеннан 12 нче номерлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләреннән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләрен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 01 сентябрендәге 540 номерлы боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2020 елның 31 августындагы 1 номерлы Бәзәкә авыл җирлегенең беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар бәяләмәсе нигезендә

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советының 2013 елның 27 маендагы 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге»

муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1 3 нче өлештә II бүлекнең 35 статьясындагы «Ж1» бүлегенең 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Күчемсез милекне рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:
- индивидуаль торак төзелеше өчен;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге);
- участоклы блокланган бергайләле йортлар;
- балалар бакчалары, башка мәктәпкәчә тәрбия объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм Кеше хокуклары буенча буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе В.С.Чершинцев